**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «13» декабреннән №50-382

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К.Исхакованың «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К. Исхакованың Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы турында мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразын хупларга.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итүне тәкъдим итәргә:
- район территориясендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру;
- базарларны киңәйтү өчен онлайн-сәүдә мөмкинлекләрен максималь файдалану өчен, шул исәптән семинарлар, консультацияләр уздыру аша, бизнеска ярдәм күрсәтү;
- кече һәм урта бизнесның сыйфатлы үсеше һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;
- милли проектларны һәм муниципаль программаларны нәтиҗәлерәк гамәлгә ашыру;
- халыкның керемнәрен һәм тормыш сыйфатын күтәрүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;
- керемнәрне легальләштерү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын үткәрү ведомствоара комиссиясе эшчәнлеге кысаларында максатчан параметрларга ирешүне тәэмин итү;
- кече хуҗалыкларга ярдәм итү һәм аларны алга таба үстерү.
4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, барлык төр милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов